# СҮЗ БАШЫ

Татар лексикографиясенең берничә гасыр дәвамында формалашкан бай традицияләре бар. Киңрәк фәнни эшчәнлек кысаларында ул традицияләр саклана, эзлекле рәвештә өйрәнелә һәм үстерелә. Хәзерге тормыш җәһәтеннән якын килеп, татарча аралашу-аңлашу ихтыяҗларын тулы һәм сыйфатлы итеп канәгатьләндерү йөзеннән, яңадан-яңа уку-укыту әсбаплары, белешмәлекләр, фәнни хезмәтләр дөнья күрә тора, мәгълүмат алмашу өлкәсендә алдынгы технологияләр эшкә җигелә, Интернет челтәре ярдәмендә телебездән файдалану мөмкинлекләре беркадәр киңәя һәм камилләшә бара. Шушы эшчәнлек кысаларында татар телен, аның лексик системасын тасвирлау, сүзләр хәзинәсенең үсү-үзгәрү юлларын барлау һәм теркәүне күз унында тотып, татарча сүзлекләр, аеруча татарча-чит тел сүзлекләрен эшләп чыгаруга да зур игътибар бирелә.

Укучыга тәкъдим ителә торган «Татарча-инглизчә, инглизчә-татарча сүзлек» – бу юнәлештә башкарылган яңа һәм оригиналь хезмәтләрнең берсе. Сүзлек Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлегендә төзелде. Аның авторлары – филология фәннәре докторы, доцент Айнур Әхәт улы Тимерханов һәм Казан федераль университеты галимәсе, филология фәннәре кандидаты, доцент Гөлшат Рафаил кызы Сафиуллина.

Сүзлекнен әһәмияте аны төзүгә этәргән берничә шарт белән аңлатыла. Татарстан Республикасы төрле юнәлештә халыкара хезмәттәшлеген җәелдерә барган саен, кайсы гына өлкәне алсак та, белгечләр арасында аралашу, тәҗрибә уртаклашу арта бара. Сәясәтчеләр, галимнәр, мәгариф һәм мәдәният хезмәткәрләре, бизнес вәкилләре, спортчыларнын халыкара конгресслар һәм симпозиумнарда, сәяси һәм икътисади чараларда, төрле спорт ярышларында катнашуы киңрәк төс ала. Чит ил ширкәтләре белән хезмәттәшлек итү өчен яңа мөмкинлекләр ачыла. Эчке һәм халыкара туризм үсүен тәэмин итүдә уңай шартлар тудырыла. Күпчелек очракта халыкара мәйданда мондый бәйләнешларда төп аралашу чарасы булып инглиз теле хезмәт итә. Җир шарында миллиард ярымнан күбрәк кешенең аралашу һәм мәгълүмат алмашу максатында нәкъ менә шушы телдән файдалануы мәгълүм. Димәк, бүген инглиз теленең таралыш мәйданы күпкә арта, киңәя бара. Бу телдә сөйләшә, аралаша алу заманча карашлы кешенең алыштыргысыз сыйфатына әйләнә. Шул рәвешле тормыш, инглиз телен белү, аңа өйрәтү белән бергә, ана телебез нигезендә ике яки күптелле сүзлекләр әзерләү бурычын алга сөрә.

Татар теле материалын инглиз теле янәшәсенә куеп төзелгән сүзлекләр, бер яктан, телләрнең бүгенге торышын, үсү-үзгәрүен, аларның тәэсир итешүе нәтиҗәләрен чагылдырса, икенче яктан, кешеләргә бер-берсенең телен өйрәнү, мәдәнияте белән танышу, аны тулырак һәм дөрес аңлау өчен кулай нигез булып тора, ягъни хәзерге вазгыятьтә тулысы белән сыйфатлы аралашуга, халыкара мәйданда аңлашуга хезмәт итә.

Шул ук вакытта глобализация тәэсирендә халыкларның милли йөзе, лингвоэтник билгеләре юылып, юкка чыга барган чорда инглиз теленә һәм башка киң таралган кайбер чит телләргә тәрҗемә аша үзебезнең бай рухи-мәдәни мирасыбызны дөнья күләмендә кинрәк, активрак пропагандалау, аның белән башка халыкларны да таныштыру максатында мондый төр сүзлекләр эшләп чыгару мөһим эш юнәлешләренең берсен тәшкил итә.

Ниһаять, төрле чорларда идеологиягә бәйле яки башка сәбәпләр аркасында нигезеннән, ватаныннан аерылып китәргә мәҗбүр булган, дөньяның төрле почмакларына сибелеп яшәгән милләттәшләребез һәм аларның варислары өчен дә татарча-инглизчә сүзлек бай мәгълүмат чыганагы булып тора, аралашуга булышлык итә.

«Татарча-инглизчә, инглизчә-татарча сүзлек» аны төзегән авторларның күп еллар дәвамында югары уку йортларында чит телләр укыту тәҗрибәсе янына лексикография өлкәсендә дистә елдан артык алып барган эшчәнлекләренең нәтиҗәсен чагылдыра. Аны төзүнең максаты – һәм татар, һәм инглиз телләренең төп сүзлек фондын тәшкил иткән гомумкулланыштагы лексик-фразеологик материалны башка телгә мөмкин кадәр төгәл һәм аңлаешлы тәрҗемә итү, шул ук вакытта һәр ике халыкның рухи-мәдәни дөньясына бәйле мәгълүматны мөмкин булганча киңрәк теркәп тасвирлау. Сүзлеккә хәзерге татар һәм инглиз телләреннән 25 меңгә якын сүз һәм сүзтемә, 2 меңләп фразеологик берәмлек теркәлде.

Әлеге хезмәтнең асыл сыйфаты – аның бер үк вакытта ике графика нигезендә – кириллда һәм латинда эшләнгәнлеге. Сүзлек рус телен белмәгән, рус язуы белән таныш булмаган кешеләр, шул исәптән тарихи ватаныннан читтә туып үсеп, шунда гомер кичерүче милләттәшләребезнең бер төркеме өчен дә иркен куллану ягыннан уңай һәм файдалы чыганак булыр дип көтелә.

Сүзлекнең лөгатьлегенә нигез итеп, «Татарча-русча-инглизчә мәктәп сүзлеге» (Казан, 2014) һәм «Инглизчә-татарча сүзлек» (Казан, 2014) алынды. Шулай ук сүзләр ике телле уку-укыту сүзлекләрендә теркәлгән лексик материалга таянып һәм сүзләрнең кулланылу ешлыгына карап сайланды. Моннан тыш һәр ике телдә дә киң файдаланылган гомум һәм көндәлек аралашу лексикасы, шул исәптән чикләнгән санда тармак терминнары, шулай ук милли мәдәният күренешләрен чагылдырган сүзләр, башка телдә тәңгәле булмаган берәмлекләр, еш очрый торган тотрыклы гыйбарәләр, актуаль мәкаль-әйтемнәр билгеле күләмдә урын алдылар. Шул ук вакытта татар теленең хәзерге үсешенә хас үзенчәлекләр, аның лексик составында яңа барлыкка килгән яисә башка телләрдән кереп үзләштерелгән берәмлекләр дә

теркәлде. Бу исә сүзлекнең, бигрәк тә татарча өлешенең лөгатьлеген тагын да баетты.

Сүзлек хәзерге татар һәм инглиз лексикографиясендә кабул ителгән принципларга таянып төзелде. Бу өлкәдә булган уңай тәҗрибә мөмкин кадәр эшкә җигелде.

Сүзлекне төзегендә, хәзерге татар һәм инглиз телләрендә гамәлдә булган орфография һәм орфоэпия нормалары нигез итеп алынды. Сирәк кенә очракларда авторлар теге яки бу татар сүзенең язылышына үзгәреш кертүне кирәк тапты.

Инглиз телендә анын бөекбритания сөйләшенә хас орфографиягә өстенлек бирелде. Шул ук вакытта сүзлектә инглиз теленең америка сөйләшендә кулланылган берәмлекләр дә урын алды, алар махсус билге белән күрсәтелде.

Вокабула сыйфатында теркәлгән татарча сүзләрдә басым нигездә нормадан тайпылыш булган, ягъни соңгы иҗеккә төшмәгән очракларда гына күрсәтелде. Инглиз телендә исә сүзнең тулы орфоэпик, акцентологик тасвирламасы транскрипция аша бирелде.

Татар фигыле *-ырга / -ергә* инфинитив шәкелендә теркәлде. Ул үзенең функциональ-семантик күрсәткечләре белән инглиз телендәге инфинитивка туры килә. Күп кенә татарча фигыльләр, бигрәк тә тезмә төренә караганнары, инглиз телендә теге яки бу фигыль белән бәйләнештә аерым бер мәгънәне белдергәндә генә кулланыла торган бәйлекләр белән бирелде.

Нигездә инглиз фигыле башлангыч инфинитив формасында мәкалә эчендә *to* кисәкчәсе белән кулланылды.

Һәр ике телдә дә фигыльнең юнәлеш, аерым очракларда затланышсыз формалары лексик мәгънә белдергәндә генә вокабула итеп теркәлде.

Шулай ук һәм татар, һәм инглиз теленә хас конверсия күренеше, ягъни бер сүзнең икенче бер сүз төркеменә караган берәмлек сыйфатында куллануы мөмкинлеге исәпкә алынды.

Шакмак билгесеннән соң (□) алфавит тәртибендә тәрҗемәләре белән компонентлары аерым язылган тезмә сүзләр һәм тотрыклы гыйбарәләргә якын торган сүзтезмә берәмлекләр китерелде.

Татар яки инглиз телендә тәңгәлләре булмаган сүзләр тасвирлама юл белән, шулай ук транслитерация аша яки ике алымны да берьюлы кулланып аңлатылды.

Сүзнең семантикасын тулырак һәм ышандырырлык итеп шәрехләү максатында кулланылган иллюстратив мисалларны һәр сүзгә яки аның һәр мәгънәсенә эзлекле китерү катгый шарт булып тормаса да, авторлар ул шартны мөмкин кадәр үтәргә омтылдылар.

Сүзлектә билгеле күләмдә башлыча беренче сүз принцибы белән фразеологизмнарга, мәкаль-әйтемнәргә дә урын бирелде. Мөмкин булганда, алар икенче бер телдәге тәңгәлләре аша аңлатылды, күп кенә очракта эчтәлеге тасвирлама юл белән шәрехләнде.

Сүзлек мәкаләсендәге грамматик, стилистик һәм башка мәгълүматны кыска, шул ук вакытта эчтәлекле һәм аңлаешлы итеп туплау йөзеннән, шартлы кыскартылмалар кулланылды. Аларның исемлеге эшләнеп, сүзлекнең кереш өлешендә бирелде.

Сүзлекнең латин графикасы нигезендә башкарылган татарча-инглизчә нөсхәсендә баш сүзләр «Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак

татар телен куллану турында»гы Татарстан Республикасы Законына (2013 елның 12 январе № 1-ТРЗ) кушымта итеп бирелгән алфавит тәртибенә туры китереп урнаштырылды. Сүзлек мәкаләсе эчендә андый тәртип катгый сакланмады. Транслитерация кагыйдәләре аерым эшләнеп, таблица шәкелендә керештә урын алды.

Сүзлек киң катлау кулланучыга – татар һәм инглиз телләрен укытучы белән яки үзлегеннән өйрәнүчеләргә, бу телләрдә сүз байлыгын арттырырга һәм белемнәрен камилләштерергә теләүчеләргә ярдәмче әсбап булып тора. Әлеге хезмәт мәктәп һәм югары уку йортлары укытучылары, студентлар, аспирантлар өчен генә түгел, инглиз телен туган тел – татар теле аша өйрәнүче, шулай ук профессиональ эшчәнлегендә чит телдән файдаланучыларның һәркайсына гамәли кулланма була ала. Сүзлекнең тәрҗемә һәм мәгълүмат чаралары эшендә дә файдалы чыганак ролен үтәячәгенә шик юк. Дөньяның төрле кыйтгаларында яшәп, туган илләрен, туган телләрен сагынып гомер кичерүче милләттәшләребезгә, гомумән, татар теле, татар дөньясы белән кызыксынган һәркемгә биредә бай һәм кызыклы мәгълүмат табарга мөмкин.

Сүзлекне төзүчеләр, хезмәтне тикшерүдә катнашып, аның эчтәлегенә карата һәм сыйфатын яхшыртуга бәйле төпле фикер-тәкъдимнәре белән уртаклашканнары өчен, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге хезмәткәрләренә, шулай ук киңәштабышлары өчен Казан федераль университеты мөгаллимнәренә һәм башка коллегаларга ихластан рәхмәтләрен җиткерәләр.

Авторлар сүзлекнең эчтәлеген, аның эшләнешен алга таба да яхшыртып булуына ышаналар һәм укучылардан аларның шуңа юнәлтелгән фикер-искәрмәләрен, конструктив тәнкыйть сүзләрен түбәндәге адреска юллауларын үтенәләр:

420111, Казан шәһ., Карл Маркс ур., 12 йорт, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, лексикография бүлеге.

Электрон почта адресы: iyali.anrt@mail.ru

*А.Ә. Тимерханов*